ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТОЙГУҖА
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

---

КАРАР

«20» ноябрь 2025 ел № 2

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа
авыл җирлегенең Тойгуҗа торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 10 ноябрендәге 1 нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә, Россия Армиясе сафларына сроклы хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны түләүдән азат итәргә.

2. алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Тойгуҗа авылында 2 (ике) данә янгын гидранты сатып алу);
- урамнарны яктырту җайланмасы: (урамнарны яктырту диодлы яктырткычлар сатып алу);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү: (Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу өчен бензин белән эшләүче триммер сатып алу; Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә үлән чабу);
- узган еллардан калган үзара салым акчаларын Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә печән чабуга җибәрергә?

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Тойгуҗа авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин